**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 апрель № 232

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен үзгәртеп кору мәсьәләләре» 2016 ел, 31 май, ПУ-491 нче Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм алардан файдалану буенча дәүләт вәкаләтләрен үтәүнең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары составын һәм мәгънәләрен раслау турында» 2008 ел, 15 июль, 499 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 3 нче пунктында, 4 нче пунктның өченче абзацында, 5 нче пунктның өченче абзацында, 7 нче пунктында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләр җирле үзидарә органнарының архив эше өлкәсендәге аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы турындагы хисап формасын раслау хакында» 2010 ел, 6 декабрь, 993 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләр җирле үзидарә органнарының архив эше өлкәсендәге аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы турындагы хисап формасының 3 бүлегендәге 3.2 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәнең 4.2 нче пунктындагы бишенче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминият фондына, Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына һәм мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондларына иминият кертемнәре турында» 2009 ел, 24 июль, ФЗ-212 нче һәм «Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминият фондына, Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына һәм мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондларына иминият кертемнәре турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актлары (закон актлары нигезләмәләре) үз көчен югалткан дип санау хакында» 2009 ел, 24 июль, ФЗ-213 нче федераль законнарны тормышка ашыру буенча беренче чираттагы чаралар турында» 2009 ел, 30 ноябрь, 818 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 август, 564 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарның 5 нче пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы; 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче; 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче; 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы; 2011 ел, 5 март, 177 нче; 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче; 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче; 2014 ел, 21 апрель, 262 нче; 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы; 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче; 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы; 2015 ел, 7 август, 575 нче; 2016 ел, 3 июнь, 370 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында нигезләмәнең 3.2 нче пунктындагы унтугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 нче Указындагы 1 нче пунктның «в» пунктчасында билгеләнгән «дәүләт хезмәтләреннән һәм муниципаль хезмәтләрдән электрон рәвештә файдалану механизмын кулланучы гражданнар өлеше 2018 елга – кимендә 70 процент» күрсәткеченә ирешү өчен дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү буенча чаралар планын раслау хакында» 2015 ел, 1 декабрь, 908 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карарның 4, 12, 13 пунктларында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 нче Указындагы 1 нче пунктның «в» пунктчасында билгеләнгән «дәүләт хезмәтләреннән һәм муниципаль хезмәтләрдән электрон рәвештә файдалану механизмын кулланучы гражданнар өлеше 2018 елга – кимендә 70 процент» күрсәткеченә ирешү өчен дәүләт, муниципаль һәм социаль әһәмияттәге хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү буенча чаралар планында:

4 бүлек исемендә, 4 бүлекнең 1, 3, 4, 6 пунктларында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче һәм 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенең 12 нче пунктында «Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 август, 625 нче; 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче; 2016 ел, 9 июнь, 375 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, башка дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат кертү регламентына теркәлгән 1 нче кушымтаның 1 нче пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 29 гыйнвар, б-133 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 19 май, б-637 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 29 гыйнвар, б-125 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында өстенлекле илкүләм проектларны тормышка ашыруда катнашучыларның үзара хезмәттәшлек итү регламентының 4 бүлегендәге 4.4 нче пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 17 гыйнвар, б-15 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Ябыла торган оешмаларның архив документларын Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль архивларына

тапшыру регламентының III бүлегендәге 3.6 – 3.8 нче пунктларда, IV бүлегендәге 4.2 нче пунктта тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 14 апрель, б-538 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының электрон почтасы рәсми адреслары исемлегендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\232.doc